# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авылҗирлегенең Олы Кайбыч торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

29 октябрь, 2019 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2019 елның 11 октябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2019 елның 12 октябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2019 елның 12 октябрендә 12 сәгать 30 минутта, 2019 елның 25 октябрендә 15 сәгать 00 минутта, 2019 елның 29 октябрендә 15 сәгать 00 минутта,узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Олы Кайбыч авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?» соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;
- материаллар сатып алып, паркны төзекләндерү;
- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып, җәяүлеләр күперен ремонтлау;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгәкитерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.»

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1226 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 655, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 654 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 1 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Олы Кайбыч торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен –дөрес дип танырга.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Олы Кайбыч авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;

- материаллар сатып алып, паркны төзекләндерү;

- җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләрне чистарту;

- материаллар сатып алып, җәяүлеләр күперен ремонтлау;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгәкитерү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:

- материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау.» - соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Кайбыч авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Б. Сафин